Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Яңа Нәдер авыл Советы

КАРАРЫ

12 май 2022 ел № 50

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Нәдер авыл Советының 2012 елның 27 декабрендәге 66 номерлы ««Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Нәдер авыл җирлегенең генераль планын раслау турында»гы карарын гамәлдән чыгару турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Нәдер авыл җирлегенең генераль планы турында» Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2022 елның 20 апрелендәге 140 номерлы карары нигезендә

Яңа Нәдер авыл Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Нәдер авыл Советының 2012 елның 27 декабрендәге 66 номерлы ««Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Нәдер авыл җирлегенең генераль планын раслау турында»гы карарын гамәлдән чыгарырга.

2. Әлеге карарны Яңа Нәдер авылы, Совет урамы, 81 йорт территориясендә урнашкан махсус стендларда игълан итәргә, шулай ук Татарстан Республикасы «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Яңа Нәдер авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Яңа Нәдер авыл җирлеге башлыгы С.М.Миңнебаев